ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 12.04.2024 508 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау, төзелешкә рөхсәтенең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә, төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 11 апрелендәге 498 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау, төзелешкә рөхсәтенең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә, төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 11 апрелендәге 498 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 2.1.1 пунктындагы «м» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«м) капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамә күчермәсен, әгәр территорияне комплексы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

шартнамә төземичә гамәлгә ашырылган очракта - территорияне комплекслы үстерү турында карар күчермәсен. Шул ук вакытта, комплекслы үсәргә тиешле территория чикләрендә капиталь төзелеш объектларын төзегән, реконструкцияләгән очракта, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын җәлеп итеп, территорияне комплекслы үстерү турында мондый шартнамәләрнең күчермәләрен бирү һәм (яисә) карар таләп ителми.».

1.2. Регламентның 2.19.1 пунктындагы «ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 70 статьясы нигезендә, территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамә яисә территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән территорияне планлаштыру документлары булмау (Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты тарафыннан мөстәкыйль сату очракларыннан тыш), әгәр капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү җирле үзидарә органы тарафыннан җирле үзидарә органы инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территориядә планлаштырылган очракта.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Э.Р.Ахмадеева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Лист согласования к документу № 508 от 12.04.2024
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 09.04.2024 14:04

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 09.04.2024 - 15:01 | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН